СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

25 июль, 1997ел.
ҖОМГА

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга.

№ 81 (8093)

Бәясе билгеләнгәнчә

## СЫЙФАТНЫ САНГА СУГЫЙК

### «Уңыш - 97» матбугат үзәге хәбәр итә

23 июльгә бер шартлы терлеккә «Таң»да 13, «Төрнәс»тә 11, Мичурин исемендәге һәм «Кондырча» хуҗалыкларында 10 центнердан артык азык берәмлеге бар иде инде. Бүген иң актуаль булган эш - сенаж салуның темпы элеккегечә үк югары булган хуҗалыклар байтак. Әмма бу эшне ничек кенә тиз тотарга кирәк булса да, сан артыннан куып сыйфатны санга сукмау һич тә гафу ителми. Кызганычка каршы, күп хуҗалыкларда базларга тутырылган сенаж сыйфат ягыннан иң югары таләпләргә җавап бирүдән ерак әле. Дөрес, әллә ничә техника эшләтмәс өчен сенаж массасын чабу белән базга кайтарып тутыруны мәслихәт күргән җитәкчеләрне дә аңларга була. Әмма бер нәрсәдә экономия кышын маллар алдына сыйфатсыз азык салырга туры килгәндә бик искә төшәргә мөмкин.

## «КОНДЫРЧА»ДА ЭШ КЫЗУ

**Көнгә - 22 кг.!**

Җәй - мул сөт чоры. «Кондырча» товарлыклы - сөтчелек фермасы сөт җитештерүне арттыруга зур игътибар бирә. Бүгенге көндә хуҗалык буенча бер сыер башыннан 22 килограмм сөт савып алынды. Ел башыннан бер сыердан савып алынган сөт 3400 килограмм тәшкил итте. Бу уңышларга ирешүдә С.Ибәтуллина, С.Бакированың куйган хезмәтләре бәяләп бетергесез.

**Маллар тук кышлар**

Бүген хуҗалыкта авыл хезмәтчәннәре һәр аяз сәгатьне эшкә җигү турында кайгырталар. Хуҗалык басуларында трактор - машина гөрелтесе тынып торганы юк, алар терлек азыгы хәзерләү белән мәшгуль. Моның нәтиҗәсе дә күз алдында. Кондырчалылар 1065 тонна печән әзерләп эскертләргә куйдылар инде. Хуҗалыкта берьеллык үләннәрдән сенаж салу, витаминлы үлән оны әзерләү дә зур темпларда алып барыла. Инде менә ничә еллардан бирле хуҗалыкта азык әзерләүдә, җыеп алуда тырыш хезмәт күрсәткән, алдынгылыкны бирмәүче абыйлы - энеле Наил һәм Илгиз Гыймадиевлар быел да басуда. Сенаж салуда төп хезмәт алдынгы шоферлар М.Төхвәтуллин, М.Сәгыйдуллин, Ш.Мөхәммәтов, Н.Фәтхетдиновка төшә. Эшне төгәл һәм төпле башкару нәтиҗәсендә, көненә 120 - 130 йөк масса сенажга салына.

**З.ӘХСӘНОВА.**

## БҮГЕН ТЫРЫШСАК, ТЫНЫЧЛАП КЫШЛАРБЫЗ

● *Бер хуҗалык хәбәрләре*

### СЕНАЖ ӘЗЕРЛӘНӘ

«Чирмешән» күмәк хуҗалыгында малларга азык әзерләү бурычы махсус кооператив звеносына йөкләнде. Кәкре Атау авылында КамАЗ шоферы Әсхать Гыйләҗев җитәкчелегендәге мондый звено мул итеп печән әзерләде, бүгенге көндә бөтен көчләрен сенаж салуга юнәлтте. ЖРБ-4,2 агрегаты белән аталы-уллы Зәки һәм Раил Садыйковлар КСК-100 тапаткычында эшләүче Сәлихҗан Садыйков һәм аның ярдәмчесе Рушат Хәлиуллинга азык культураларын урып, кырларны әзерләп торалар, ә ике КамАЗчы, берсе-Фәнил Садыйков, ЗИЛ белән Дамир Хәлиуллин, Т-150 дә Илдар Хәсәнҗанов, МТЗда Фәнил Сәгыйров һәм Камил Сөнгатуллин әзер азыкны базларга ташыйлар. Ә анда аларны Рамил Кыямов каршы ала һәм Т-150 тракторында сенажны тыгызлап таптатып тора. Һәр минутның кадерен белеп, тырышып эшләү соңгы чиктә уңай нәтиҗәләрен бирәчәк: кооперативчыларның эш хакы да нәкъ шул ахыр нәтиҗәгә карап түләнәчәк бит. Шул ук звено хуҗалыкта башка төр азык-салам, силос хәзерләүне, ахырдан басу кырыйларын чистартып калдыруны үз җилкәләренә алалар. Нәкъ шундый ук звено Гәйтән авылы бригадасында да оешты һәм алар да актив рәвештә сенаж сала башладылар. Бу җаваплы эштә звено җитәкчесе Николай Акмуллин, Андрей Клементьев, Сергей һәм Виктор Уфимовлар, Сергей Осипов, Николай Сандрявкин, Александр Романов мәшгульләр. Алар малларга азык әзерләү өчен көчләрен кызганмыйча эшләргә ниятли. Бүгенге көндә ике бригада егетләре тырышлыгы белән 800 ләп тонна сенаж салынды инде.

### АБЗАРЛАР ҮЗГӘРТЕЛӘ

Хуҗалыкның товарлыклы-сөтчелек фермаларында тулы куәткә реконструкция бара. Башлыча, абзарлар малларны салкын һәм бәйсез тоту ысуллары белән асраута күчүгә әзерләнә.

## «ДОН»нар һөҗүмгә әзер

### Районда комбайннарның уракка әзерлеге парады булды

Уракка төшәр көннәр дә килеп җитте. Быелгы уракның башка еллардагыдан төп үзенчәлеге уңышның елдагыдан мул күтелүе булганга күрә, комбайн паркының, бигрәк тә сугуда эшләячәк комбайннарның бу мөһим кампаниягә ничек әзерләнгәнлеген белеп тору да, аларны кабат энә күзеннән үткәреп, шул кыр корабларында эшләячәк капитаннарның кәефен белешү дә мөһим иде. Шул нияттән район җитәкчелеге быелгы уракта эшнең иң авырын үз җилкәләренә алачак «ДОН»нарны өч кустка җыеп аларның әзерлеген абруйлы комиссияләр составында тикшереп кабул итүне оештырды. Сишәмбе көн «Үрнәк» һәм «Заветы Ильича» хуҗалыклары басуларында һәм Норлатта сабантуй мәйданында барлык хуҗалыклардан да «ДОН»нар җыйналды. Норлаттагы парадта МТС каршындагы җыелма отряд составындагы комбайннар һәм предприятиеләрдән, оешмалардан урак чорына хуҗалыкларга булышка тартылган автотранспорт та сынау узды. Барысы бер рәткә тезелгән һәм һөҗүмгә кузгалырга әзер торган сугышчан техниканы хәтерләткән ул кыр корабларына (парадка сиксәннән артык «ДОН» чыкты) һәм автомашиналарга (алары илледән артык иде) ерактан бер күз төшереп алу гына да быелгы уракка районда зур көч тупланганлыгына инандыра иде. Әле бит куәтле ул кыр корабларының капитаннары кемнәр диген! Күбесе элегрәк тә, былтыргы уракта да таң калдырырлык иттереп эшләгән, берсеннән берсе бай тәҗрибәле оста игенчеләр. Һәркайсы үзенең кыр корабын быел да сынатмаслык иттереп әзерләү өчен мөмкин булганның барысын да эшләгән. Әнә, узган елгы урак батыры Рәшит Насыйбуллин комбайнын кыш буена иренмичә ремонтлаган һәм аның быел да ниятләренең чынга ашасына өмет зур. Александр Донсков, Рәфыйк Вафин, Әхәт Ибраһимов, Илсур Абдуллин, Салих Бикиев, Юрий Гордюнин, Аркадий Кузьмин һәм башка бик күпләр үз комбайннарын зур горурлык белән эшләтеп күрсәттеләр. Район авыл хуҗалыгы идарәсенең инженерлык һәм агрономия службалары, «Сельхозтехника» АҖ, дәүләт автомобиль һәм янгын инспекцияләре белгечләре составындагы абруйлы комиссия һәр агрегатны җентекләп тикшереп чыкты. Шунысы гыйбрәтле, быелгы уракның киеренке буласын аңлап, чарасына керешкән хуҗалыкларда «ДОН»нарның барысын да парадка өлгертүгә ирешкәннәр. Әлмәт хуҗалыгы алты, «Киекле» 5, Рассвет», Хафизов исемендәге хуҗалыклар дүртәр комбайнны тулы әзерлеккә китереп алып килгәннәр иде. «Игенче»нең өч «ДОН»ына карата да комиссиянең дәгъвасы булмады - җитәкчелекнең эшкә чын-чынлап алынуына мисал түгелмени бу. Һәм мондый мисалларны бик күпләп китерергә мөмкин иде. Әмма уракта бар өмет шуларда булган «ДОН»нарын бүгенгә кадәр тәртипкә китереп бетерә алмаган хуҗалыклар да булуы борчылырлык. Бүтәннәр биш - алтышар комбайнны өлгертә алган бер вакытта бердәнбер «ДОН»нарын кеше күзенә күрсәтерлек хәлгә китерә алмаган хуҗалыклар да бар иде бит арада. Уракны нинди көч белән башкарып чыгарга уйлый торганнардыр алар. Дөрес, МТСның җыелма отряды тулы әзерлектә бүген, район җитәкчелеге комбайн паркын тагын да тулыландыру буенча да эшлекле чаралар күрә. Әмма мобиль отрядлар уракта зур файда китерсәләр дә, берсе дә рәхмәткә генә эшләмәячәк бит, шактый акчаңны яки ашлыгыңны чыгарып салырга туры киләчәк. Ә авыл халкының бар өмете әлегә шушы икмәкне җыеп алып урнаштыра алсак, шактый акчалы булачакбыз. Шуңа күрә дә район хакимияте башлыгының беренче урынбасары Ю.В.Терентьев, район авыл хуҗалыгы һәм азык - төлек идарәсе башлыгы Р.М.Гыйбадуллин комбайннарын парадка алып чыккан механизаторлар алдында чыгыш ясап, быелгы уракның барьяклап та хәлиткеч булачагы һәм ул көрәштә комбайнчыларга зур өмет багълануы турында әйтеп, бу кампаниядә алардан зур оешканлык һәм җаваплылык белән эшләү соралуын тагын бер тапкыр кабатлап үттеләр.

Урак чорында хуҗалыкларга ярдәмгә тартылган автотранспорт та җентекле смотр узды бу көнне. Иң күп (15) автомашина куйган автотранспорт предприятиесе, 14 машина чыгарган УТТ, 4 машина куйган ДРСУ, икешәр - өчәр машиналарын уракка җибәрәчәк күп кенә башка оешмаларның техникасы ышанычлы булуы билгеләп үтелде. Хәзер аларны беренче әмер булу белән эшкә тотынырлык иттереп герметиклаштырып кую турында кайгыртасы гына. Әмма монда да билгеләнгән кадәр автомашина әзерләп өлгертә алмаган оешмалар да бар иде. Барыбыз өчен дә олы нигъмәт булган икмәк язмышы өчен көрәш тә уртак эшкә әверелсә яхшы һәм районда бу мәсьәләдә авыл белән шәһәр арасында моңарчы нык булган дуслык быел да какшамас дип ышанасы килә.

**Р.МУЛЛИН.**
**Н.АЗИЗОВ фотосы.**



# «САВУЧЫГА ТУН КИЛЕШӘ!»



## Район сыер саву осталары слетыннан

Рәсемнәрдә: слет барышыннан күренешләр.

Ямьле Тигәнәш аланы үз гомерендә бәйрәмнәрне күп күрде, шулай да хезмәт кешесен алиһә бөеклегенә күтәреп хөрмәтләү, аңа ихтирам хисләре белән сугарылган мондый олысын, мөгаен, ул да беренче очраткандыр. Ул һәртөрле товартулы сәүдә лареклары, сый - нигъмәтләр тезелгән табыннар, сәхнәдән агылган дәртле, моңлы җырларда гына да түгел, ул савучылар слетының бар рухында, бар кәефендә чагыла иде. Мөгаен, бу атмосфера район саву осталары слетын ачып, аларга котлау сүзе белән мөрәҗәгать иткән район хакимияте башлыгы Фатыйх Сәүбән улы Сибагатуллин чыгышыннан башлангандыр.

Ул авыл фидакарьләренең хезмәте каршында баш иеп, аларның иң зур кадер - хөрмәткә лаек булуларын ассызыклады һәм район хакимиятенең киләчәктә шул хөрмәтне күрсәтергә тырышачагын нык тавыш белән ышандырды. Слет кунаклары - «Востокмонтажгаз» АҖсе генераль директоры В.В.Бартынев, Мари - Эль республикасы совхоз директоры В.М.Медведков, «Анар» мех әйберләр җитештерү фирмасы директоры урынбасары В.И.Муллинның килү максатлары да район авыл эшчәннәре тормышына игелек кылу ниятеннән иде, үзләре дә күңелгә ятышлы, вәгъдәләре дә өметле яңгырады. (Авылларыбызга табигый газ, нәселле терлекләр генә түгел, затлы туннар да кирәклеген без соңрак үзебез күреп инандык).

Әйе, лаек, бик лаек иделәр слетта катнашучылар бу олылауга. Бу авыл хуҗалыгы һәм азык - төлек идарәсе начальнигы чыгышында китерелгән кайбер саннарда да ачык чагыла иде. Район алты айда сөт җитештерү буенча республикада 8 урынга менде, быелгы кышлату чорында һәр малдан узган елгы дәрәҗәдән 440 кг.га артыграк продукция алынды. Хәзер район бер сыерга сөт җитештерү буенча республикада 4, аны сату буенча I урынны алып тора. НГДУның «Дуслык» ярдәмче хуҗалыгында 9 айда һәр сыердан 4563 кг., «Кондырча» КХАсында 4378 кг. сөт саудылар. Терлекчеләр алдында торган бурычлар да катлаулы. Быел районда бер шартлы терлек башына 40 азык берәмлеге исәбеннән азык хәзерләү мөмкинлеге бар, бу исә районда сөт җитештерүне сыер башына уртача 3600 - 3800 кг.га җиткерү бурычына хезмәт итәчәк. Әлбәттә, төп хезмәт, һичшиксез, терлекчеләр - иң әүвәл савучылар җилкәсенә төшәчәк. Шуңа да слетта хатын - кызларыбыз адресына яңгыраган һәр сүз, һәр мактау, һәр хөрмәтләү табигый һәм урынлы тоелды. Әмма сюрпризның иң олысы алда булган икән әле. Менә авыл хуҗалыгы идарәсе начальнигы:

- Сәхнәгә НГДУның «Дуслык» ярдәмче хуҗалыгыннан Рәмзия Таһир кызы Җаббарованы чакырабыз,- дип игълан итте.

Һәм шунда хакимият башлыгы кулына елкылдап торган кара тунны алып, савучыга кигерде, үзе үк төймәләде дә. Бу күренештән таң калган мәйдан беравык тын торды, аннан гөрләтеп кул чапты. Фамилияләрнең яңалары атала торды. «Дуслык»тан Мәрьям Гыймадиева, «Рассвет»тан Зәйнәп Сатдарова, Мичурин исемендәге КХАдан Людмила Николаевна Михеева. «Төрнәс»тән Нурания Галимова һәм башкалар - барысы 20 савучы бу көнне сәхнәдән затлы мутон һәм кайры туннар киеп төштеләр. Ничек күңелең тулмасын да, ничек күңелең булмасын ди мондый зурлауга?

Ә затлы кием авыл кешесенә дә килешә икән! Кул чабулар астында үз урыннарына юнәлгән савучыларның йөзе генә түгел, адымы да үзгәргән сыман тоелды безгә. Бу бүләк алучыларга гына түгел, гомерләрен шушы хезмәткә багышларга җыенган яшьләргә аеруча көчле тәэсир ясагандыр, безнеңчә. Аннан соң сәхнәгә күтәрелгән алдынгы Мичурин исемендәге, «Кондырча», «Дуслык» хуҗалыклары җитәкчеләре, баш белгечләр дә бүләкнең затлыларына лаек булдылар.

Ә бәйрәм дәвам итте. Сәхнәдә - республикабызның танылган артистлары, яшь талантлар берсен - берсе алыштырып кына тордылар. Авыл эшчәннәре яраткан Хәния Фәрхи, Асаф Вәлиев, Резидә Шәрәфиева, Лидия Әхмәтова һ.б. белән кабат очрашудан күңелләре булды, кушылып җырладылар да, түгәрәккә төшеп биеделәр дә. Тантанада тәүге тапкыр Р.Шәрәфиева башкарган «Норлатым» җырын да бик җылы кабул иттеләр. (Аның сүзләрен Н.Гыйматдинова, көен Г.Сәйфуллин язган, соңгысы аны район хакиме соравы буенча махсус язылуын үзе үк әйтеп китте). Арырак алар өчен «Анар», «Сунар», «Альбарс» фирмалары теккән мех әйберләре сатылды, уеннар оештырылды, НГДУ ОРСы, райпо, тимер юлчылар

ОРСы пешекчеләре аларны тәмледән - татлы ризыклары белән сыйлап кына тордылар.

Таралышканда һәммәсе шат, канәгать иде.

- Хакимебез «елда һәммәгезне туннарга төрәм»,- диде. Шулай зурлап әйткән сүзеннән үк күңелебез үсеп, җаныбыз җылынып кайта»,- диделәр апайлар берсен - берсе бүлә - бүлә.

- Безнең хезмәтне аңлаган, бәяли белгән кеше кул астында эшләве дә күңелле. Ходай исәнлеген бирсен, бергә - бергә озак эшләргә язсын,- дип өстәделәр икенчеләре.

Авыл кешесе риалана белми, ул күңелдәгесен әйтергә күнгән. Үзен зурлаган кешегә җанын ярып бирергә, йөз кызартмаслык хезмәт куярга әзер ул. Савучылар моны киләчәктә дә аңларлар әле.

С.ХӘЙРУЛЛИНА.




## Җил дә исмәс, яңгыр да яумас

7 сентябрьдә Мәскәүнең 850 еллык юбилеен бәйрәм итәргә җыеналар. Бу көнне табигать законнары буенча яңгыр яварга тиеш булса да, ул... яумаячак. Чөнки бәйрәмне уздыру программасына Мәскәү өстенә ябырылган болытларны махсус кудырып тору чарасы да кертелгән. Моның өчен махсус самолетлар һәм вертолетлар кулланылачак. Мәскәүдә берничә дистә километрда очу аппаратларыннан яңгыр явуны булдырмый торган каты углекислота яки йодлы көмеш тузаннары очырылачак.

Мәскәү бәйрәменә Русия төбәкләреннән, БДБ һәм Балтик буе илләреннән 660 кешелек 167 делегация киләчәк. Аларны «Националь» һәм «Русия» кунакханәләре кабул итәчәк. Делегация җитәкчеләре бер кешелек (бәясе 1 млн. 804 мең. сум) һәм 2 кешелек (2млн.359мең) бүлмәләргә урнаштырыла. Мондый дәрәҗәдәге кунакларны тукландыру өчен көненә 115 мең сум исәбеннән акча тотылачак.

Делегатларга хезмәт күрсәтү өчен 14 «Мерседес», 14 «ГАЗ-31» җиңел автомашинасы бирелә. Бер «Мерседес»тан бер сәгать файдалану 160 мең. сумга төшәчәк. Делегация җитәкчеләренә 400 мең сумлык сувенир, 350 мең сумлык чәчәк бәйләме бүләк ителәчәк.

## Рәхәтләнеп эшләгез

ТРның Авыл хуҗалыгы һәм азык - төлек министрлыгы биргән заказдан һәм 3,5 миллиард сум акчадан «Элекон» фәнни - җитештерү берләшмәсе һәм Казан механика заводы эшчеләренең шатлыклары «күлмәкләренә сыймый». Бу предприятиеләр моңарчы чит илдән сатып алынучы 150 агрегат эшләп бирергә тиеш.

## Мәскәү елгасы холера белән авырый

Холера вибрионын анда бер атна элек тапканнар һәм Мәскәү суын куллануны бөтенләй тыйганнар. Елга буйлап көне - төне арлы - бирле катер йөреп тора, тавыш көчәйткеч аркылы халыкка коену, балык тоту гына түгел, кул юарга да ярамавы турында тукып торалар.

## Әллә марҗа аласы...

Тамбов өлкәсе Думасы 14 яшьтән үк язылышырга рөхсәт бирә торган Закон кабул итте. Димәк, дәртләренә чыдый алмаган 14 яшьлек татар егетләренә Тамбовка барып марҗа алырга мөмкин. Без - Русия гражданнары да бит, димәк, каршылык булмаячак.

# СӘЛАМ ӘТЛЕК

**№1**

● **КИҢӘШЛӘР**

## Халык медицинасы

* Артык майлы ризык ашап костырса, ярты лимон согына ярты балкашык чәй содасы эретеп эчәләр.

* Уникеилле эчәк җәрәхәтеннән кан килсә, бер йомырка агына бер балкашык шикәр пудрасын һәм бер аш кашыгы зәйтүн маен яхшылап туглап, ач карынга берәр аш кашыгыннан ун көн эчәләр.

* Ашказаны һәм уникеилле эчәктәге җәрәхәтләрне дәвалауда халык медицинасында кулланыла торган бер ысул:

бер аш кашыгы каймак, бер аш кашыгы бал, бер данә чи йомырканы яхшылап болгаталар да иртән ашка кадәр 20 минут элек эчеп җибәрәләр. Көн саен иртән генә эчәләр.

* Күп хатын - кызлар аякта кан тамырларының киңәюеннән интегәләр. Моны дәвалауның гади генә юлы бар. Өлгереп җиткән помидорны телемләп кисәләр дә кан тамырларына тезеп бәйлиләр һәм җиңелчә генә чеметтерә башлаганчы тоталар. Аннары аякны бераз салкынча (әмма салкын түгел) су белән чайкыйлар. Аяклардагы зәңгәр таплар беткәнче процедураны кабатлап торалар.

* Сөялне авыртусыз гына бетерүдә әремнең ярдәме зур. Киптерелгән 3 - 4 аш кашыгы әрем порошогын бер стакан кайнап торган суга салып 45 - 50 минут тоталар. Шуны көнелә берничә тапкыр сөялгә сөртәләр.




**ӘСТӘГЪФИРУЛЛА!**

# Ике тамчы су кебек

Америка галимнәре шаккатыргыч ачыш ясаганнар. Күз алдына китерегез, бер табиб Марта исемле хатынның кулыннан кечкенә генә тире кисеп ала да күкәй күзәнәк эченә урнаштыра. «Ясалма аналык»та чын кеше организмы формалаша башлый...

Яңа «туган» бала башкалардан аерылып тормый, әмма иң гаҗәбе, ул ике тамчы су кебек әнисенә охшаган була. Алай гына да түгел, әнисенең балачагын, язмышын кабатлый башлый. Марта үзен чиксез бәхетле хис итә, чөнки язмышын алдан белгәнгә кызны тәрбияләү ансат булачак.

Табиб Станц әлеге ачыш турында бер ел буе беркемгә дә сөйләми. Ә хәзер бөтен газеталар бу гаҗәп операция турында шаулый. Фән әһелләре исә хәзергә дәшмиләр. Галимнәрне, сәясәтчеләрне, киң җәмәгатьчелекне башка нәрсә борчый: әгәр дә эксперимент дәвам итеп, дөньяда бер - берсенә охшаган бәндәләр күбәйсә, нишләргә? Алай гына да түгел, шушы юл белән даһилар тудыра башласалар, кешелекне нәрсә көтә? Аннан соң үз карынында үсмәгән балаларга аналарының карашы ничек булыр?

Февраль аенда президент Клинтон мондый операцияләр үткәрү өчен дәүләт акчасын бирмәскә дигән карар чыгарган чыгаруын, әмма хосусый клиникалар әлеге экспериментны дәвам итәргә мөмкин бит. Шуның өстенә кысыр гаиләләр балалы булыр өчен берниндИ акча да кызганмаячаклар.

Хәер, «ясалма аналык»та бала үстерергә теләүчеләр дә, каршы килүчеләр дә хәзер берни эшли алмаячаклар. Яңа гына бер уфологик сектаның Багам утрауларында махсус коммерция фирмасы ачуы билгеле булды. Әлеге секта җиргә тереклек галәмнән килгән дип исәпли, галимнәр, сәясәтчеләр сүзенә колак та салмый. Һәм бүгеннән үк кеше күчермәләрен эшләүне җайга салырга җыена. Шуның өстенә, әлеге фирмада балаларның күзәнәкләре дә сакланачак. Монысы берәр бала белән бер хәл булган очракта аны яңадан «тудыру» өчен инде. Директор Брижит Буаселье әйтүенчә, күзәнәкләрдән олы кешене дә яңадан тудырып булачак. Мондый операция 50 мең доллар торачак икән. Әлеге фирма якын илләрда бөтен җир шарыннан 1 миллион клиент кабул итәргә әзер.

# Урыс кызына Канада йөрәге

Ярославль сәламәтлек саклау департаментына Канададан Настя Патрикеева өчен дип акча килде. Бу - «Известия» гәзитендә йөрәк авыруыннан газаплаучы балалар турында («Клиническая смерть», 234) язылган мәкаләгә җавап иде. Шул мәкалә нигезендә Канада телевидение компаниясе Ярославльдән тапшыру әзерләгән иде. Анда күрсәтелгәннәрдән Настя Патрикеева язмышы күпләрнең күнелен тетрәтте. Аның әнисе үлгән, әтисе яңа гаилә корган. Настя әбисе белән генә аның зур булмаган пенсиясенә яши икән.

Беренче булып Монреаль шәһәреннән Мария Алексис ярдәм кулы сузган, 3000 Канада доллары җибәргән. Аннары Нос Бэй шәһәреннән дүрт бала анасы Кэролин Кеннеди 1000 доллар акча салган.

Настяга Бакулев исемендәге йөрәк - кан тамырлары хирургиясе институтында операция ясау 26 миллион 727 мең сумга төшә. Тик шунысы кызык, канадалылар ярдәменнән соң ук Өлкәнең үзәгендәге страховой компанияләрдә 22 авыру балага да операция ясатырлык акча табылган.

**(«Мәдәни җомга» газетасының 18 июль санынннан).**

# Балан чәе



Баланның кеше организмына уңай тәэсире күптән билеле. Балан чәен болай ясыйлар: кирәк кадәр балан җимешләрен савытка салып, өстенә кайнап торган су коялар. Һәм шул чәйнең күңелне күтәреп җибәрүен берничә йотым эчү белән үк сизәрсез. Балан канны чистарта, бавыр өчен бик файдалы Гипертония белән авыручылар өчен дә алыштыргысыз. Ләкин кан басымы түбән кешеләргә балан чәе белән артык мавыгырга киңәш ителми. Аларга көненә бер стакан чәй җитә.

Балан җимешләрендә күп микъдарда пектин матдәләр бар, ә алар кеше организмыннан холестерин һәм авыр металларны куып чыгаралар. Шуңа күрә кышка күбрәк балан әзерләгез.

# Кемгә ялган, кемгәчын



Янып торган шәм белән кешенең рухи халәте арасында тыгыз бәйләнеш бар дип санала.

Әгәр кешенең тормышы тәртиптә икән, шәм биек ялкын белән, акмыйча гына яна. Ләкин инде эчке дөньяңда нииндидер тынгысызлык яки берәр авыру булса, эрегән шәм аның стенасы буйлап яшь кебек агып төшә. Әгәр дә шәмнең өстеннән аска кадәр бер генә сызык агып төшсә, бу кешегә каргыш төшкән, ә инде икәү булса, ике тапкыр каргалган була.

Сызыклар бер - берсен кисеп «х» рәвешендә агып төшсә, бу кешене каты авырудан соң үлем көтә. Әгәр дә янып торган шәм белән сәгать теле юнәлешендә кеше тәне буйлап йөртсәң һәм берәр урында шәм кара төтен чыгара башласа, аның шул тирәдәге эчке органнары авырый дигән сүз һәм ул тирәләрне инде кара төтен күренми башлаганчы дәваларга кирәк.

Шәмне һәрвакытта да кешенең гел бер ягына гына каратып торырга кирәк. Эрегән «яшьләр» аның ягыннан акса - бөтен авыруларында ул үзе гаепле. Ә инде кире яктан акса, бу кеше белән аның дошманы арасында энергияләр көрәше бара дип санала. Шәм үзе дугасыман бөгелеп төшсә, кешегә явыз көчләр иялешкән.

Хәер, шәмгә карап кына үзеңнең авыруларың, язмышың турында белеп булмый инде ул. Бу сүзләргә бик ышанмаска киңәш итәбез.

# Яраткан төсләребездә үзебез чагылабыз

***Кызыл төс*** - дәрт, теләк, рухлану төсе. Бу төсне яраткан кеше кыю, ихтыярлы, хакимлек итәргә яратучан, тиз кызучан һәм аралашучан. Күбесенчә - альтруист (кешеләргә яхшылык итәргә теләүче).

***Кызгылт сары*** - интуициягә ия һәм хыялланырга гаять һәвәс кешеләрнең яраткан төсе.

***Сары*** - кешеләр белән мөнәсәбәттә үзен тыныч, иркен тотучанлыкны һәм интеллегентлылыкны белдерә.

***Алсу*** - тормыш төсе, ул яратырга һәм игелеклерәк булырга ихтыяҗны күрсәтеп тора.

***Кызгылт көрән*** - төсне һәм аның барлык төсмерләрен тормышта ныклап аякка баскан, традицион йолаларны, гаилә мөнәсәбәтләрен нык ихтирам итүче кешеләр өстен күрә.

***Яшел*** - өметләр һәм ачык юллар төсе.

***Зәңгәр*** - күк төсе, аны гадәттә кешенең рухи күтәренкелеге, аның сафлыгы белән бәйлиләр.

***Ак*** - аны капма - каршы холыклы кешеләр дә үз күрә. Үзенең киемнәрендә, йортында бу төскә өстенлек бирүче кешенең пөхтә - җыйнак булуы, чисталыкны яратуы турында сөйләп тора.

***Кара*** - ышанычсызлык төсе, тормышны караңгы төсләрдә күрү символы.

***Соры*** -озак уйлап эш итүчән, ышанмаучан, тиз рәнҗи торган кешеләр өстен күргән төс.

**ВИТАМИН АШАГЫЗ!**

# Башлы кәбестә салатлары



1. Кәбестәне вак итеп һәм токмач шикелле кисәргә, кишер һәм алманы зур угычта уарга, вак итеп туралган суган кушарга. Тәмена карап, шикәр комы, тоз, аз гына аш серкәсе өстәргә дә көнбагыш мае белән озак кына бутарга. Бу салатны алданрак ясап кую зарур.

Ярты килограмм кәбестәгә 1 эре кишер, 1 алма, бер суган, бер чәй кашыгы шикәр комы, 0,5 чәй кашыгы серкә алына. Тоз, май тәмәнә карап.

2. Кәбестәне вак итеп һәм токмач кебек кисәргә дә, алманы (бер алма) угычта уып, суганны ярты түгәрәк рәвешендә турап, аз гына шикәр комы, тоз кушып, майонез белән бутарга.

# Мүк җиләге



Базарда мүк җиләге еш күренә. Әлбәттә, язга таба туңдырылган мүк җиләгендә витаминнар бик аз кала. Ләкин органик кислоталар, пектин матдәләре тулаем саклана.

Мүк җиләге җимешләрен килегә салып төегез. Шул массаны кайнар суга болгатып эчегез, тәнегезгә көч, күзләрегезгә нур иңгәнен сизәрсез.

# Тынгысыз июль

Июльнең беренче яртысы криминаль вакыйгаларга бай булды. Шуларның иң күңелсезе - өч кеше үлеме теркәлүе булды. 4 нче июльдә кислород станциясе территориясендә В. батып үлде. Ә 16ында Норлатның Куйбышев урамында яшәүче ир - ат һәм Киекле авылында хатын - кыз мәете табылды. Көчләү билгеләре күзәтелмәде.

***

Тыныч тормыштан туеп сугыш мәйданы оештыручылар, анда яраланучылар да аз булмады.

5 июльдә Киекледә яшәүче Р. авылдашлары тарафыннан кыйнала. Иртәнге сәгать 6 нчы яртыда ул баш мие кузгалу диагнозы һәм гәүдәсенең төрле җирендәге яралар белән Иске Чаллы шифаханәсенә китерелә. Нәкъ шундый ук диагноз белән 9 нчы июльдә тагын ике кешегә дәваланырга ятарга туры килә. Берсе норлатлы, ә икенчесе югары норлатлы. Шул ук көнне Биляр Озеро авылында яшәүчеләр группасы сугышып В.Хәмидуллинны кыйныйлар. Хәер, читтән килүчеләр дә норлатлылардан кыен алып киткәлиләр. Шулай, 7 июль төнендә Әлмәттән килгән Прокопьевтан гариза керә.

Кеше байлыгы белән баерга теләүчеләр дә тыныч ятмыйлар. Элемтә бүлегендә эшләүче К. халык кулына тапшыра торган акчаларның бер өлешен кесәсенә шудыра бара. Нәтиҗәдә сумма шактый түгәрәкләнә - 3 млн.га якын сумга җыела. Кем белә, тотылмаган булса, ул аннан да узар иде.

14 нче июльдә билгесез кешеләр Нефтьчеләр урамындагы бер фатирны көпә - көндез ватып керәләр. Нәрсә алырга? Өйне әйләнеп, барлап чыкканнан соң, күзләре келәмгә һәм хрусталь савыт - сабаларга тукталып кала. Чыкканда күрерләр дип тә шикләнмиләр, өйләреннән ташыгандай күтәренеп чыгалар. Соңрак караклар ачыклана. Ә менә Дружба урамындагы берәүнең йортыннан «шестерка»сын урлап китүчеләр бернинди эз калдырмыйлар.

Запас часть юк, техника ремонтланмый. Болар авыл хуҗалыгында күптәнге һәм хәл ителмәгән мәсьәлә. Ә менә Кузнецов исемендәге һәм «Правда» КХАларында аны урып - җыю кампаниясе алдыннан тагын да кискенрәк итәргә теләгәннәр булса кирәк: беренчесендә ДТ - 75тән 7 радиатор салдырып алсалар, икенчесеннән «Нива» комбайнын һәм Т - 4 тракторын чишендереп киткәннәр. Тикшерү бара.

# Котлыйбыз!

*Хөрмәтле хезмәттәшебез* ***Гыйният Гыйльман улы Камаловны*** *тормышындагы олы вакыйга - 50 еллыгы белән кайнар котлап, саулык, озын гомер, чиксез бәхет телибез.*



*Туган көннең ямьле мизгелләре*
*Күңелегездә калсын уелып.*
*Тәбриклибез Сезне чын күңелдән*
*Барыбыз да бергә җыелып!*

***Бикүле урта мәктәбе коллективы.***

## Белдерүләр



### Сатабыз

**Норлат сәүдә базасында түмәрләп һәм ваклап 19 меңнән шифер, 64 меңнән рубероид, 50 кг.лы төргәге 350 мең сумнан сүс, капчыгы 30 меңнән цемент, 1,3 кг.мы 17 мең сумнан олифа, 1 кг.мы 11 меңнән тавык ботлары.**

**Ашыгыч төстә ВАЗ - 2105, кыйммәт түгел, гараж өчен чана**. Адрес: Школьная ур., 14 - 1.

***

**Ашыгыч рәвештә 1981 елгы әйбәт хәлдәге ВАЗ - 2103, кыйммәт түгел**. Адрес: 60 лет Октября ур., 10 - 2.

***

**Яңа «Муравей» мотороллеры**. Тел.: 5 - 25 - 63.

***

**Әйбәт хәлдәге ВАЗ - 2121.** Тел.: 5 - 24 - 45 яки 2 - 14 - 70 (18 сәг., тән соң).

***

**Азык комбинаты янында бәрәңгесе белән 6 сутый дача участогы**. Адрес: Советская ур., 183 - 101.

### Төрлесеннән

***Сафронов Владимир Ефимович исеменә документлар белән сумка табучыны бүләк бәрабәренә Гыйматдинов ур., 60 - 13 адресы буенча иясенә кайтаруын сорыйбыз.***

***

**Яшь гаиләгә фатир кирә**к. Тел.: 3-62-56.

***

***«Уют» чикле җаваплылыктагы ширкәте ябыла. суыткычларын ремонтка бирүчеләрнең 1 ай эчендә заказларын яңабаштан яздыруларын сорыйбыз. Ремонтка суыткычлар кабул итү иске адрес буенча.*** Адрес: Советская ур.,103.

***

**Ананьев Геннадий Егорович исеменә документлар салынган сумканы бүләк бәрабәренә иясенә кайтаруларын сорыйбыз**. Адрес: Куйбышев ур.,39-3.

### Алыштырабыз

**Норлаттагы 2 бүлмәле фатир Аксубайда шундый укка яки сатыла.** Пушкино поселогы Пимурзиннарга мөрәҗәгать итәргә.

***

**Казанда Идел Ярында Обсерватория станциясендә кирпеч йорт-Норлатка. Газы, суы кергән, мунчасы,гаражы бар. Вариантлар мөмкин**. Тел.: 2-19-77.

***

**Кормыш микрорайонында 2 һәм 1 бүлмәле фатирлар- 3 бүлмәлегә алмаштырыла.** Тел.: 5-16-44

***

**Тимер юлчылар мәктәбе янында мунчасы, капиталь гаражы, 7 сутый бакчасы булган йорт - шәһәрнең теләсә кайсы районында фатирга**. Тел.: 5 - 15 - 01.

***

**Язуы белән мәрмәр һәйкәлләр, траур ленталары әзерлибез, бәясе - килешү буенча, китереп бирергә мөмкин**. Адрес: Ленинградская ур., 14. Таныклык: Б - 324.

***

**Мостафин Равил Рифкатович исеменә паспортны, югалу сәбәпле, гамәлдән чыккан дип исәпләргә.**

***

**Югалган страховой таныклыкны (формасы номеры - 281, сериясе ГБ № 1215379) гамәлдән чыккан дип исәпләргә.**

### Ярминкәгә чакырабыз

***29 июль көнне 8 сәгатьтә район мәдәният йортында Ульяновск күн комбинаты аяк киемнәре сату буенча ярминкә үткәрелә. Киң ассортиментта ирләр, хатын - кызлар, балалар аяк киемнәре, галантерия товарлары бар.***

## Кулыгыздан куаныгыз!

### Кафель плитә ябыштыру



Әгәр кафель плитәләрне стенага, мичкә ябыштырсагыз, цементны бер өлеш, комны 4 өлеш, ә идәнгә җәйгәндә 1,5 өлеш итеп алалар. Мондый плитәләрне майлы буяу белән дә ябыштыралар. Бу очракта буяуны бер - ике мм. итеп сылыйлар плитәнең тигез өслеккә каплыйлар. Плитә артына бер - ике урынга кечкенә генә пластилин кисәкчәләре ябыштырсаң, ул плитәне буяу ныгыганчы үз урынында яхшы тотып тора.

Кафель кубып төшсә, аны ацетон һәм пенопласт ярдәмендә ябыштыру уңай. Плитәнең дүрт почмагына да зурлыклары 20 х 20 х 20 мм. булган пенопласт шакмаклар куеп чыгалар. Пипетка белән һәр шакмакка 20 - 25 тамчы ацетон тамызалар. Берничә секундтан пенопласт эри. Шуннан соң плитәне җайлап кына алып стенага нык итеп басып ябыштыралар.

Шушы ук ысул белән аяк киеме табаннарын, ленолиум, паркет һәм башка материалларны да ябыштырып була.

# Аякларың төзгенә, тимәс микән күз генә?



***Аңлагансыздыр, шәт, сүз - аяклар турында. Яшерен - батырын түгел, хатын - кызның хәл - әхвәле, кәефе, шәхси тормышы, кайчак хәтта хезмәт хакы да аякларының нинди булуына нык бәйләнгән.***

***Матур аяклар - һәммә хатын - кызның хыялы. Тик менә ходай ниндине бирә бит әле. Ничек булса да, аяклар мәсьәләсенә ярым шаярып, ярым чынлап карый белегез. Теләсә нинди аякны матур итәргә мөмкин. Киңәшләребез менә шул хакта. Рәхәтләнеп файдасын күрегез.***

Аякларның төрләрен билгеләүдән башлыйбыз:

**1. Озын аяклар.**

Үкчәләрне бер - берсенә якын итеп куегыз һәм тезләрне туры тотып, алга иелегез, куллар белән идәнгә кагылырга тырышыгыз. Кагыла алсагыз, димәк, кулларыгыз озын, кагыла алмасагыз - радикулит. Аяк озынлыгы болай үлчәнми. Гадәттә, озын буйлы хатын - кызларның аягы озын була. Әмма урта буйлыларның да аягы озын булырга мөмкин. Бу очракта гәүдәнең пропорциясе һәм аякларның башка өлешләргә карата озынрак булуы күзгә тиз ташлана.

**2. Пропорциональ аяклар.**

Аякларыгыз 1,3 нче төргә карамаса, нәкъ шундый булалар.

**3. Кыска аяклар.**

Аякларыгыз тиешле югарылыкка җитә алмыйча тиз генә янбашка әверелә икән, димәк, алар чыннан да кыска. Берничә киңәш:

- биле түбән күлмәкләр һәм киң итәкләр кимәскә,
- үкчәле (бик биек булмаса да ярый) аяк киемнәре сайларга,
- озын аяклы ханымнардан көнләшмәскә, чөнки озынлыктан башка аякның формасы һәм тулылыгы да зур әһәмияткә ия.

**4. Нечкә аяклар.**

Биредә берничә вариант булырга мөмкин: нечкә, сөякчел, буыннары күренеп торган аяк. Әмма мондый аяк сез уйлаган кадәр ямьсез түгел. Киңәшләр:

- кара оеклар белән сак кыланыгыз, аякларыгыз төз булмаса бигрәк тә,
- кыңгырау рәвешендәге итәкләрне кию катгый тыела,
- бөтенләй үкчәсез туфли (үлчәме зур булса бигрәк тә) сезне бизәми,
- ачык төстәге оеклар һичшиксез килешер. Нечкә, ябык аяклылар да моны исендә тотсын,
- сезнең аякларыгызга тыгыз бәйләнгән оеклар яки ачык төстәге кунычлы оекбашлар (гетры) кию әйбәт,
- артык биек үкчә белән мавыкмагыз,
- кайбер очракларда киң балаклы чалбар кия аласыз.

**5. Юан аяклар.**

Бар җире дә юан булган аякларны карап үтик. Сүз уңаеннан, күп кенә ир - атлар әз - мәз генә юан аякларны ошата. Әгәр дә артык юаная башласалар, һичшиксез, көрәш ачарга кирәк. Диетага утырырга, аэробика, шейпинг белән шөгыльләнергә. Боларны укыгач йөзегез җыерылган икән, хәзер үк укудан туктагыз. Безнең киңәшләр корыч ихтыярлы яки кияүгә чыгу теләге бик көчле булганнар өчен генә:

- юан аяклыларга караңгы төстәге оеклар гына килешер (ак һәм аксыл соры оекларны алып та тормагыз),
- артык биек булмаган үкчәле туфли кияргә,
- бик үк кыска булмаган туры киселешле итәк (бераз ерыгы булса да ярый) киеп йөрү мәгъкуль күрелә.

БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**

МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА**

Учредительләр: Октябрь район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.

"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.

Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Норлат шәһәре, Карл Маркс урамы,19.

Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, җаваплы сәркәтип - 2-18-67, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия,реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.

*Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.*

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2306 данә Заказ N 7189